ГОД ЦИФРОВИЗАЦИИ В РЕСПУБЛИКЕ ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫНДА ЦИФРЛАШТЫРУ ЕЛЫ

Г.Тукай ис. Мөслим урта гомуми белем бирү мәктәбе

# Тукай ялкыны

“ Туган телне сөючеләр” пресс-центры **Март, 2024 нче ел** №6




Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнехановның 8 Март – Халыкара хатын-кызлар көне уңаеннан мөрәҗәгате.

Кадерле хатын-кызлар! Сезне 8 Март — Халыкара хатын-кызлар көне белән тәбрик итәм!

Хатын-кызлар халыкның күпчелек өлешен тәшкил иткән һәм иҗтимагый тормышта гаять мөһим роль уйнаган безнең илдә бу бәйрәм гаиләнең буыннга тапшырыла килгән рухи хәзинәләре какшамаслыгын, Ана мәхәббәте дигән бөек хиснең изгелеген, мөлаемлык, чибәрлек һәм нәфислек өлгеләрен күңелләргә тагын да ныграк сеңдерергә тиешле киң колачлы зур тантана төсен алды.

Борын-борыннан шагыйрьләр һәм рәссамнар хатын-кызга багышланган сүз-гыйбарәләрнең һәм образларның иң тәэсирлеләрен сайларга омтылган. Гүзәл затларны алар үзләрен иҗатка илһамландыручы алиһәгә тиңләгәннәр, тылсымлы йолдызларны, серле тауларның иң биек нокталарын, яңа ачылган, үзләштерелмәгән җирләрне аларның исемнәре белән атаганнар. Дөньякүләм үзгәрешләр һәм космик тизлек чорында — бүген дә без хатын-кызларның күркәм хасиятләренә ихластан сокланабыз.

Кояшлы көндәй нурлы, ягымлы «әни» сүзе һәрберебез тарафыннан аерым кадер һәм наз белән әйтелә. Мәңге үзгәрмәс хакыйкать дип танылган һәр нәрсәне без ана сөте аша канга сеңдерә, туган телнең могҗизага тиң көйле агышын ота барабыз һәм чиксез кыйммәтле бу рухият гомерлек юлдашыбызга әйләнә, аны балаларыбызга, оныкларыбызга кадерле мирас буларак тапшыра киләбез. Туган телләр һәм халыклар бердәмлеге елында яшьләрне ана теленә, күпмилләтле туган республикабызга һәм бөек Россиягә хөрмәт һәм мәхәббәт рухында тәрбияләү өчен гаилә традицияләренә мөрәҗәгать итү аерым әһәмият ала.

Сугыш дәһшәтен, хәрабә хәленә китерелгән сәнәгатьне, авыл хуҗалыгын торгызуның бар авырлыгын үз җилкәсендә күтәргән мәшһүр хатын-кызларыбыз — өлкән буын вәкилләренә халкыбыз хакына башкарган бөек эшләре өчен чиксез ихтирамыбызны белдерәбез. Аларның батырлыгы хәтеребездә мәңге сакланыр.

Ирләр белән бер үк сафта күп айлар дәвамында мәкерле чиргә каршы көрәш алып барган батыр хатын-кызлар — медицина хезмәткәрләренә эчкерсез рәхмәт сүзләремне җиткерәсем килә. Кешеләр гомерен саклап калу өчен кылган игелекле гамәлләрегез, шәфкатьлелек һәм миһербанлылык, сабырлык кебек асыл сыйфатларыгыз мактауга һәм данлауга лаек.

Хәзерге заманда, тормышның нинди генә өлкәсен алма, сез — ханым-туташлар, беренчелеккә омтыласыз. Иҗтимагый эшчәнлектәге, мәгариф, житештерү өлкәләрендәге, мәдәният, фән һәм спорттагы уңыш-казанышларыгыз безне сөендерә, кайчак хәтта таң калдыра. Матурлык һәм акыл, сөйкемлелек һәм тырышлык хас булганлыктан, сезнең барлык уй-ниятләрегезне чынга ашырырга, теләкләрегезгә ирешергә көчегез җитәрлек дип уйлыйм.

Кадерле хатын-кызлар, тормышыгыз сөенечтән балкып торсын, һәрчак якыннарыгызның, гаиләләрегезнең җан җылысын тоеп яшәгез! Сезгә нык сәламәтлек, бәхет, иминлек, муллык телим!

Тулырак: [https://alabuganury.ru/news/v-respublike/rostam-minnexanov-pedagoglarny-ukytucylar-kone-belan-kotlady](https://alabuganury.ru/news/v-respublike/rostam-minnexanov-pedagoglarny-ukytucylar-kone-belan-kotlady)

## Мәктәп яңалыклары...

Профориентация айлыгы кысаларында 9-11 нче сыйныф укучылары Яр Чаллы шәһәрендә урнашкан КАИ уку йорты вәкилләре белән очраштылар. Укучылар югары уку йорты факультетлары, кабул итү кагыйдәләре белән таныштылар.



3 нче чирек йомгаклары буенча линейкалар узды. Төрле конкурсларда җиңү яулаган, макулатура җыю буенча 1,2,3 урыннар алган класслар бүләкләнде. Язгы каникулда нинди чаралар үтүе, куркынычсызлык кагыйдәләре белән таныштырылды.



Всероссийское родительское собрание "Россия - мои горизонты"21 марта МБОУ "Муслюмовская СОШ им.Г.Тукая" проведено Всероссийское родительское собрание "Россия - мои горизонты". В нем приняли участие родители учащихся 6-11 классов.Цель данного собрания - дать родительскому сообществу информацию о том, чем и для чего занимаются их дети в рамках профориетационных мероприятий.Перед коллективом родителей выступила педагог-навигатор проекта "Билет в будущее" Л.М.Халиуллина. Лайсан Максутовна познакомила родителей с целями Единой модели профориентации,задачами курса "Россия - мои горизонты" и региональными возможностями развития образовательно-профессиональной траектории. Родителям были показаны видеоролики.В видеоролике об эксперта проекта "Билет в будущее" Кузнецов К.Г. дал 5 советов о том, как помочь ребенку сделать правильный выбор.Так же родители получили памятки и рекомендации по работе с разделом " Родители" на платформе "Билет в будущее".В конце собрания все участвующие в нем пришли к общему выводу,что совместная работа педагогов и родителей поможет ребятам найти свой путь в жизни и определиться в мире профессий.

## ӘНИЛӘР БӘЙРӘМЕ.

**1А.Алып баручы: Хәерле көн безнең иң кадерле кунакларыбыз - әниләребез, әбиләребез, сеңел һәм апаларыбыз! Көннең яктылыгы – кояшта, күкнең матурлыгы – йолдызларда, җир йөзенең гүзәллеге – хатын-кызларда. Сезне чын күңелдән шушы җир йөзен бизәгән хатын-кызлар көне белән тәбриклибез.Бәйрәмнең кайсы да җанга ял алып килә. Шушы бәйрәм көне, елмаеп баккан кояшның матурлыгын, табигатьнең самимилеген өстәп, күңелегезгә шатлык, тәнегезгә сихәтлек, өегезгә иминлек алып килсен. Бүген җил дә йомшак исә, Кояш та назлы көлә. Бүген җиргә иң-иң якты**
**Кадерле бәйрәм килә.**
**2 А.Кадерле Әниләр! Сезне Әниләр бәйрәме белән тәбрик итәбез. Бердәнбер иң кадерле, иң хөрмәтле, иң якын кешеләребез - Әниләр!Балаларыгыз турында гел яхшы сүзләр генә ишетеп яшәргә язсын Сезгә! Чөнки әниләр өчен моңардан да зуррак бәхет юк! Матур булсын, котлы булсын бәйрәмегез!**
**1 А: Әниләр бәхетле булсын өчен, баланың да бәхетле булуы кирәк. Без әниләрне рәнҗетмичә, аларга кайгы-хәсрәт китермичә яшәргә өйрәнергә тиеш.**
**2 А: Без чыгышыбызны Сания Әхмәтҗанованың "Мин бәхетле булыр өчен тудым" дигән шигырен укып башлап җибәрәсебез килә.**
**Алып баручы: Безнең бүгенге бәйрәм уеннар формасында үтәчәк. Уеннарны бәяләү өчен жюри кирәк була. Жюри члennары белән танышып китик:**
**1 Уен: Мәкальнең башы минем тел очында, ахыры кемдә икән?**
**Ата йөрәге — таудан өлкән Ана йөрәге-( диңгездән тирән.)**
**Ана күңеле балада,...(бала күңеле далада)**
**Ата-ананы тыңлаган –( адәм булган, тыңламаган — әрәм булган)**
**Бишектәге –(бишкә төрләнер.)**
**Әткәй — шикәр, әнкәй —( бал.)**
**Ана балага авызыннан (өзеп каптырыр.)**
**Ана яхшылыгын (авырсаң белерсең.)**
**Атаның каны, ананың (сөте)**
**Ана сүзен тотмаган, олыгайганчы ( игелек күрмәгән)**
**Яктылык – кояш янында, яхшылык – ( ана янында)**
**Ана куены ( туннан җылырак)**
**Баланың бармагы авыртса, ананың ( йөрәге авырта)**
**Алып баручы: Әни җирдә иң газиз, якын кеше.Чөнки ул сине тудырган, күкрәк сөтен имезгән, җыр көйләп бишектә тирбәткән, беренче елмаюыңны күреп куанган, туган телне өйрәткән, халык моңын күңеленә сеңдергән... Әниләрнең сиңа кылган изгелеген санап бетерү мөмкинме соң?**
**2 Уен: Бишек җырын башкару.**
**Алып баручы: Нинди уңган безнең әниләр. Матур итеп бишек җырын да башкаралар. Әйе, алар бит шул җырларны җырлап нәни балаларын йоклатканнар, аларны үзләрен дә кайчандыр кадерле әниләре бишек җыры белән юатканнар.**
**Алып баручы: Һәрбер хатын кыз бу дөньяда матурлыкны ярата, яисә инде гөлләр, чәчәкләр яраталар алар.Чәчәкләр бит алар матурлык бирүчеләр.**
**3 Уен: Төсле битләрдән чәчәк ясау**
**Алып баручы: Хәзер кайсы бала әнисенә күбрәк матур сүз әйтә алыр икән шуны тикшерик әле. Башта битләргә язып чыгыгыз, аннан бер-бер артлы әйтеп барырбыз.**
**4 Уен. Әниеңә матур сүзләр әйт.**
**Алып баручы: Әни балага, бала әнигә кадерле. Үз балабыз өчен кайгырабыз, аңа иң яхшы теләкләр телибез. Әйдәгез әле, әниләр үз балаларыгызны табып карагыз. Сезнең күзләрегезне бәйлибез һәм сез балаларны кулларыннан тотып танырга тиеш буласыз.**
**5 Уен. Балаңны танып ал.**
**Алып баручы: Әни кеше бөтен һөнәргә дә уңган була. Үз эшен дә, ир-ат эшен дә оста башкара. Бала өчен аның газиз әнисе иң яхшы биюче, иң яхшы җырлаучы һәм бар яктан да иң-иң яхшысы. Хәзер безнең әниләр үзләренең осталыгын күрсәтеп китәрләр.**
**6 Уен: Иң оста биюче Әни**
**Алып баручы: Сезнең балаларыгызны үзегездән дә яхшырак белүче юк. Кая нинди яра, кая нинди миң дисеңме, күзенең төсе, борыны нинди, авызы нинди дип сорасалар да уйламыйча дөресен җавап бирәсез. Хәзер сез Әниләр, оста рәссамнар булмасагыз да, балаларыгызның рәсемен ясарга тиеш буласыз. Ә сез, балалар, Әниләрегезне сүрәтләгез.**
**7 Уен: Әниләр һәм балалар портреты**
**Алып баручы: Галимәр баланың көнгә ничә сорау бирүе белән кызыксынганнар. Берничә ананың киеменә кечкенә микрофон һәм тавыш яза торган аппарат урнаштырганнар. Нәтиҗә: 4 яшьлек бала көнгә уртача 440 якын сорау бирә икән. Шулчаклы сорауга җавап кайтарып бетереп кара әле син!**
**8 Уен: Табышмакларга җавап тап.**
**Тик менә, ашарга гына пешерә белмим тәмле, җитмәсә бөтен ярмалар кушылган.**
**9 Уен: Ярмаларны аер.**
**Алып баручы: Мактаулы безнең әниләр**

**Кадерле әниләр!**

**Бәйрәмегез сезгә бәхет,**
**Сәламәтлек китерсен,**
**Көнегез гел шат булсын,**
**Елның һәрбер көне Сезгә**
**Әниләр көне булсын!**




**Алып баручы: Сүзне жюрига бирәбез.**

20 нче март көнне авыл мәктәпләре директорлары өчен чираттагы стажировка үтте. Мәктәбебезгә Баланны, Баек мәктәпләре җитәкчеләре килде. Бүгенге кунакларыбыз да мәктәп эшчәннәре белән таныштылар һәм хезмәтебезгә бик югары бәя бирделәр.



"Киләчәккә билет" профориентация проектын гамәлгә ашыру кысаларында бүген "Россия үсешендә: булган, булачак" темасына сөйләштеләр. 89 субъект арасында иң зур төбәк - Саха Республикасы. Иң кечкенә төбәк - Төньяк Кавказда Ингушетия. Шулай ук, илебезнең төрле өлкәләрдәге иң зур казанышлары турында белделәр.Викторинада катнаштылар



Мәктәбебездә Май чабу бәйрәме узды! Директорның тәрбия эшләре буенча киңәшчесе А.И. Хафизова, педагог-оештыручы Р.З. Бухарова, педагог-китапханәче А. И. Миргалимова башлангыч сыйныф укучылары өчен саф һавада бәйрәм оештырдылар. Хоровод әйләнү, уеннар, аркан тарту кебек ярышлар уздырылды Бәйрәмнең финалы булып директорның тәрбия эше буенча урынбасары Г. Ф. Мәүлиева пешергән коймаклар белән сыйлану булды! Балалар күңел ачтылар, биеделәр, уйнадылар.



"Алдынгылар хәрәкәте" нең район башлыгы каршында советы үтте. Советта хәрәкәтнең төбәк бүлеге баш белгечләре Гөлфия Абдуллина һәм Әмил Ибадов катнашты. Тәрбия буенча директор киңәшчесе Алисә Хафизова, Сөмбел Ибраһимова хәрәкәт эшчәнлеге буенча чыгыш ясадылар.

Өр яңа "Нурлы мәктәп" проекты үзенең эшен башлап җибәрде. Әлеге проектның максаты мәктәбебезнең сәләтле, белемле укучылары белән таныштыру. Беренче кунагыбыз- Максутов Ринат

.

**Укучыларыбыздан килгән хатлар...**

**Әнием.**

**Әни... Әнием... Нинди ягымлы һәм йөрәккә якын бу исем! “Әни ”дип эндәшә алу – үзе зур бәхет ул. Мин – дөньяда бик бәхетле бала, чөнки янәшәмдә минем өчен җан атучы, сөенгәндә шатлыгымны уртаклашучы , кочагына сыенганда: ”Кызым, йөрәк җимешем!” –дип иркәләп эндәшүче газиз әнием бар.**

**Әни! Һәр кеше өчен иң кадерле, иң хөрмәтле, иң якын кеше ул. Авыр чакларыбызда да, шатлыклы минутларыбызда да без әниләребезнең җылы кочагына сыенабыз. Әниләрнең йөрәк җылысы, “Балам!” дип эндәшкән ягымлы сүзләре безгә яшәргә көч бирә. Йомшак куллары белән башыңнан бер сыйпап узса, бөтен авыруларың, борчуларың беткән кебек була. Әнә шундый тылсымлы, бөек көчкә ия ул- ана дигән изге зат.**


**Әгәр без бүген зәңгәр күктә йөзгән ак болытларга, кояшлы җылы яңгырларга, түбәләрдән тып-тып итеп тамган язгы тамчыларга карап сөенәбез икән, без моның өчен әнкәйләребезгә бурычлы. Чөнки алар - безгә бу матур дөньяны бүләк итүчеләр, төнге йокыларын йокламыйча, җил-яңгыр тидермичә безне үстерүчеләр. Димәк, алар – безне яклаучыбыз да, саклаучыбыз да.**

**Минем үземнең әнием турында язып үтәсем килә. Һәркемгә үз әнисе дөньядагы иң кадерле кеше булган кебек, миңа да үз әнием − кадерлеләрдән дә иң кадерлесе. Барлык балаларныкы кебек, минем дә телем "әни" сүзе белән ачылган. Әниемнең йомшак куллары, ягымлы тавышы, моңлы җырлары миңа шатлык китерә.**

**Әнием безгә тәмле-тәмле ризыклар пешерә, кичен назлап йоклата, ә иртән "кызым" диеп сөеп уята. Әни булганда , өебез нурлы, аның күзләреннән бөркелгән нур һәрберебезгә җылылык бирә. Әнием янәшәсендә булганда гына мин үземне бәхетле хис итәм. Әнием кешеләргә карата шәфкатьле, ягымлы, ярдәмчел булырга өйрәтә, минем миһербанлы, шәфкатьле , акыллы булып үсүемне тели. Әниемнең биргән киңәшләре җанга дәва бирә, киләчәккә ышаныч уята, яшәү дәрте бирә.**

**“Җәннәт -аналарның аяк астында,” -диләр. Әйе, бу дөрестән дә шулай. Һәрбер ана үзенең йөрәк җимеше - баласы өчен кайгырып яши. Үз чиратыбызда , без дә, әниләребезне яратып, аларга кайгы-хәсрәтләр китермичә яшик. Әниләребезнең йөзләреннән беркайчан да елмаю чаткылары сүнмәсен иде. Барыр юлларыбызны яктыртып торучы, мәңге сүрелмәслек кояшыбыз бит алар безнең. 8 нче сыйныф укучысы Әсәдуллина Айзилә**

**Әниемнең исеме – Лилия. ❁ Нинди матур исем ул?! Исеменә туры килгәндәй, әнием үзе дә матур һәм акыллы.**
**Һөнәре буенча ул укытучы. Укытучы булу җиңел түгел. Минемчә, бик күп белергә һәм балаларны яратырга кирәк. Әнием мәктәптә эшли, башлангыч сыйныф укучыларына белем өләшә. Һәрбер баланы укырга, язарга өйрәтә. Эше аның бик авыр, шул ук вакытта җаваплы. Аны укучылар да ярата, ихтирам итә.**
**Ял көннәрендә без авылга кайтабыз. Анда әниемнең әнисе, минем дәү әнием яши. Әнием безне генә түгел, үз әнисен карарга, хөрмәтләргә тырыша. Без дә нәнәебезгә булышабыз. Җәйге ялда аның янына бик еш кайтабыз.**
**Әнием безне бик ярата. Апам Адилә да аңардан үрнәк ала. Өй эшләрен бик яратып башкара, әниемә ярдәм итә. Менә шундый ул минем әнием! 10 нчы сыйныф укучысы Гыйльметдинов Ислам**



**Әни… Өч хәрефтән торган бу сүздә күпме җылылык! Һәр кеше өчен иң кадерле кеше ул! Аның йомшак куллары миңа кагылуга, бөтен кайгылар югала. Ә „улым” дип аркамнан сыйпаса, миңа гүя очар канатлар үсә. Ә сүзләре шундый татлы, җылы.**

**Минем әнием Гөлнара исемле. Аңа 35 яшь.Ул шундый матур, кара чәчләре үзенә бик килешеп тора. Әле ул бик уңган. Нинди генә эш эшләми әни куллары! Тәмле итеп ашарга да пешерә, безне дә тәрбияли. Минем әнием төрле һөнәрләргә дә оста: массаж да ясый, балаларны йөзәргә дә өйрәтә.Үзе турында да онытмый ул: спорт белән дә шөгыльләнә.**

**Менә шундый әнием булганга, мин бик бәхетле. Мин аны бик яратам.**


**Мөхәммәт пәйгамбәрнең: “Һәр бөек эшнең артында хатын-кыз тора. Ул уң кулы белән бишек, сул кулы белән бөтен дөньяны тибрәтә”, — дигән сүзләре һаман актуаль булып кала. Хатын-кыз нәфис иңенә, бала карау, гаилә мәшәкатьләреннән тыш, ил хәстәрен дә ала. Гүзәл затларыбыз җәмгыятьнең төрле даирәләрендә үзләрен белемле белгечләр, яхшы хезмәткәрләр итеп таныта. Көндәлек эшеннән тыш, хатын-кыз ул — милләт анасы. Әйе, болай атау һич арттыру түгел. Әни кешенең бурычы — баласының тамагын тук, өстен бөтен итүдә генә түгел, ә нарасыен милләтенең асылташы итеп тәрбияләүдәдер. Баланың теле әнисе сөйләшкән телдә ачыла. Бу — бер. Икенчедән, бала үз халкының гореф-гадәтләре, дини бәйрәмнәре, йолалары тәэсирендә дә тәрбияләнергә тиеш. Ә аларны кем бирә? Әлбәттә, әни. Үзенең телен, милли традицияләрен, тамырларын белгән балалар тәрбияләү — һәр ананың бурычы. ”Дөньяга килгән сәгать белән балалар тәрбиягә мохтаҗлардыр. Боларны тәрбияләүчеләр дә — аналардыр. Аналар балаларның һәр эшләрен гадәткә салырлар. Тәрбияле аналар — олуглар алдында эшләргә ярамаган эшләрне балалар алдында эшләмәсләр вә сөйләргә ярамаган сүзләрне сөйләмәсләр, моннан бик сакланырлар. Шулай ук балаларның хәйләгә, ялган сөйләргә өйрәнүләренә сәбәп булырдай нәрсәләрне кылмаслар”, — дип әйтелә ”Тәрбияле ана” исемле хезмәтендә. Аллаһының мең рәхмәте яусын сезгә, кадерле әниләр! Айгөл Миргалимова, китапханәче.**


















# Укучыларыбыз иҗаты

**7”б”сыйныфы укучылары яза...**
**Әниемә әйтер сүзем бар...**

**Рәфил Баһауов:**
Әни кеше шәфкатьле, күңелле, яратучан һәм дини булырга тиеш.Минем әни бик яшь тә түгел һәм бик карт та түгел. Минем әни ялкау түгел, ләкин башы авыртканда эшләргә иренә. Мине әни ярата, булыша, кайбер авыр вакытта коткара. Мин әниемә озын гомер, исән- саулык, бәхет һәм мең савап телим.

**Соломатин Рамазан**:
Әни- матур, ямьле,тырыш, яхшы күңелле, ярата белә, ашарга пешерә, эшли, булыша, өйрәтә торган кеше. Минем әнием Роза, аңа 41 яшь Ул “Азалия” магазинында эшли. Минем әнинең холкы әйбәт, “2”ле алсам, әз генә кисәтү ясап ала. Әнием минем матур эш эшләргә ярата. Күп үсемлекләр үстерә, аларны бик ярата. Мин әниемә гел матур һәм ачык йөзле булуын телим. Күп талашмасын, үзенең хыялларын ачыкласын. Гел ямьле булсын һәм бөтен өйдәге балаларны яратып торсын.

**Әһлиев Самир:**
Әни безнең өчен онытылмаслык, матур, ягымлы булырга тиеш. Ул һәр минут ярдәм итәр. Син аны сагынырсың һәм гел сагынып торырсын. Әниләр безнең өчен иң якын, иң чибәр, иң гүзәл кешеләр. Ул синең бердәнберең. Әниләрнең характерлары бер инде, алар акырырга булдыра, әгәр син әшәкеләнсәң, тыңламасаң. Әниләр алар гел матур киенәләр. Алар сезнең өчен нык чибәр. Аларның матур түгел чаклары юк. Булмый да.

**Муртазин Ислам:**
Әниләр - алар игелекле, матур кешеләр, балачактан тәрбиялиләр, кирәк булганда һәрвакыт булышалар. Минем әнием иң матур, ягымлы сары чәчле хатын, аңа 35 яшь. Ул мине үстерде һәм мине тумыштан ук яклады, әнием бик акыллы һәм уңышлы, ул булдыра ала. Миңа берәр нәрсә авыр булса булыша. Мин әниемә шул ук матур, игелекле кеше булып. калуын һәм һәрвакыт елмаеп кына йөрүен телим.

**Шәмсимөхәммәтов Илгиз:**
Минем әниемнең исеме- Айзирә. Ул бик матур, акыллы, кайгыртучан. Әнием: игелекле, кайгыртучан, акыллы, һәрвакыт ярдәм итә һәм ярдәм итәчәк. Ул чәчәкләрне ярата, өйдә үстерә. Ул минем һәр очрак өчен борчыла. Миңа һәрвакыт булыша. Әни безне үстергән, ашаткан, киендергән игелекле, матур кеше. Минем әниемнең характеры идеаль. Минем әниемнең чәчләре ак-кара, күзләре көрән, ул 160 озынлыкта. Мин әниемә хәзерге кебек гомер буе шундый матурлык телим. Шул ук игелек, кайгырту, аны гомере буе озатсын, матур елмаюы бервакытта да йөзеннән китмәсен. Аның авырмавын, һәркемгә ярдәм итүен телим.

**ШиһаепавРайнур:**
Әниләр матур, тырыш, кайгыртучан булырга тиеш. Минем әниемнең исеме- Нина. Ул бик тырыш эшчән. Минем әниемә теләкләрем: чирләмәсен, тырыш булсын.

**ЗакировРөстәм:**
Жир йөзендәге иң кадерле кешеләр- ул безнең әниләребез. Чөнки, алар безне туганнан бирле яратып, тәрбия биреп үстерделәр. Минем әнием- Илиза. Ул усалрак булса да, безне бик нык ярата. Берәр ялгышлык эшләсәк, кисәтеп тә ала инде.Ул бер эштән дә куркып тормый. Без авыр хәлдә булганда безнең хәлгә кереп ярдәм итә. Әнием бик сөйкемле,чибәр, гел матур киемнәр генә кия. Минем әниемә саулык, сәламәтлек һәм иң изге теләкләр генә телисем килә.

**ГалиевРамазан:**
Әни, әнием, энкәем! Минем әнием! Кеше үз гомерендә шул сүзне ничәмә-ничә кабат әйтә икән? Телебез ачылуга да әйткән сүзебез “ӘНИ” бит безнең. Чөнки безне дөньяга тудырган, күкрәк сөтен имезгән, без авырганда төннәр буе, йокыларын качырып, янәшәбездә саклап утырган, беренче елмаюыбызны күреп куанган, беренче тәпи атлап киткәнебезгә чын күңелдән сөенгән, безнең өчен йөрәген бирердәй булып яшәгән кешебез ӘНИ безнең. Үскән саен, әни сүзе безгә яңадан-яңа мәгънә алып килә. Тора-бара без аның үзебез өчен иң кадерле, иң якын кешебез икәнне аңлыйбыз. Нинди генә борчулар килеп чыкса да, нинди генә уңышларга ирешсәк тә, иң беренче булып серләшкән кешебез әни, чөнки без беләбез – ул һәрвакыт безнең янәшәдә һәм беркайчан да ялгызыбызны гына калдырмаячак.Кечкенә чагыбызда да, олыгайгач та кирәк әле безгә әни назы, әни карашы. Ничә генә яшьтә булсак та, нинди генә уңышларга ирешсәк тә, янәшәбездә гомеребез буе таянып яшәгән кешебез – Әни һәрчак кирәк. Күп кенә иптәшләрем берәр киңәш кирәк булса, дусларына мөрәҗәгать итәләр, ә мин әнием белән киңәшләшәм. Әниемнең назлы тавышы, йомшак куллары башка кешедә юктыр. Әниемне ничек итеп ятратканымны сүз белән генә әйтеп бетерә алмыйм. Аның кайгыртучан карашы, җылы сүзләре, акыллы киңәшләре җанга рәхәтлек бирә. Мин әниемә бик рәхмәтле!!!

**ХарисовРенат:**
Ана – бөек исем ! Бу сүзләргә бик әз кеше лаек дип уйлыйм мин . Чөнки , чын әни булу өчен , бик каты көч куярга кирәк . Кем соң ул әни ? Бу сүзләрне төрле кеше төрлечә аңлый . Минемчә, ана кеше - ул балаларга наз бирүче (йөрәк җылысын), давыллардан саклап килүче, аларны тугрылыкка, шәфкатьлелеккә, ярата белергә өйрәтүче яки бөек аякка бастыручы, кыен чакта баш имәскә өйрәтүче бөек кеше. Нинди генә анаң булмасын, син аны яратырга, хөрмәт итәргә тиешсең. Чөнки кешенең әнисе баласы нинди генә булмасын барыбер ярата. Тик дөньяда төрле кешеләр очрый шул кайсыберләре әниләрен хөрмәт итә, ә кайсыберләре юк. Минем шуны әйтәсе килә: әнинең барлык туганнарның кадерен белеп яшәгән кеше генә дөньяда иң бәхетлесе була .

«Тукай ялкыны”, март, 2024 нче ел, Г.Тукай ис.Мөслим урта мәктәбе укучылары газетасы Баш мөхәррир: Гайнетдинова Г.Ф.
Корреспондентлар Нуреева Алия, Җаббарова Диана
Дизайнер Әсәдуллина Айзилә. Компьютерда җыючы: Галеева Камилә, Миргалимова Эльвина .Гамәлгә куючы: Г.Тукай ис.Мөслим урта мәктәбе укучылар иҗат үзәге Адрес: Мөслим, Тукай 21 Электрон адрес: s2.mus@mail.tatar.ru 100 экземпляр.